РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентябрь 2026 ел г. Альметьевск № 1647

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Мәдәният идарәсе ведомствосындагы
муниципаль учреждениеләрнең
мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы
функцияләрен һәм вәкаләтләрен
гамәлгә ашыручы орган белән аеруча
кыйммәтле күчемле мөлкәткә кертелгән
сәхнә мөлкәтен арендага яисә
түләүсез файдалануга тапшыруны
килештерү тәртибен раслау турында

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, Спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яисә стационар сәхнә җиһазына караган һәм дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына оператив идарә хокукында беркетелгән дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата күрсәтелгән мөлкәттән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 24 сентябрендәге 1610 номерлы карары белән расланган театраль-тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чараларында файдалану өчен дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә төзү кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе ведомствосындагы муниципаль учреждениеләрнең мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә кертелгән сәхнә мөлкәтен арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерү тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Әлмәт хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

заказ № 4553-940

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Мортазинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» сентябрь 20 26 ел №1647
карары белән расланган
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе ведомствосындагы муниципаль учреждениеләрнең мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә кертелгән сәхнә мөлкәтен арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерү тәртибе

1. Әлеге Тәртип спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яисә стационар сәхнә җиһазына караган һәм оператив идарә итү хокукында мәдәният оешмаларына беркетелгән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәтне конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә арендага, түләүсез файдалануга тапшыру (алга таба – аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәт), күрсәтелгән мөлкәттән театраль тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чараларында файдалану өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе ведомствосындагы муниципаль учреждениеләр (алга таба – мәдәният оешмалары) һәм мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган белән белән килештерү процедурасын билгели.

2. Мәдәният оешмалары тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 3 өлеше нигезендә конкурслар һәм аукционнар үткәрмичә генә, «Спектакльне (тамашаны) яисә стационар сәхнә җиһазларына караган һәм оператив идарә хокукында дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән, күрсәтелгән мөлкәтне театр-тамаша, мәдәни-агарту яисә мавыктыргыч-күңел ачу чараларында файдалану өчен әлеге мөлкәтне театр-тамаша чараларында һәм күрсәтелгән мөлкәт төрләре исемлегендә куллану өчен аренда шартнамәләренең, дәүләт яисә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәләренең конкурсларын һәм аукционнарын үткәрмичә генә төзү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 24 сентябрендәге 1610 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә, шартларда һәм спектакльнең (тамашаның) сәхнә бизәлешенә яисә стационар сәхнә җиһазларына караган мөлкәт төрләре исемлеге нигезендә төзелә.

3.Мәдәният оешмасы юридик зат яисә физик зат, шул исәптән индивидуаль эшкуар буларак теркәлгән зат (алга таба - хуҗалык субъекты)тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата шартнамә төзү турында гариза алынган көннән алып 5 эш көне эчендә хуҗалык итүче субъектка аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерү турында мөрәҗәгатьне (алга таба – мөрәҗәгать) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитетына язма рәвештә җибәрергә тиеш.

4. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хуҗалык итүче субъект исеме, урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы, контакт телефоны номеры;

2) арендага, түләүсез файдалануга тапшырырга тәкъдим ителә торган

аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт турында белешмәләр (исеме, инвентарь номеры (булган очракта), баланс бәясе, техник характеристикалар һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка белешмәләр);

3) аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, аренда түләве күләме төзү тәкъдим ителә торган срок;

4) хуҗалык итүче субъект аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән файдаланырга ниятләгән театраль-тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чаралары турында белешмәләр.

5. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар кушып бирелә:

1) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата шартнамә төзү нияте турында хуҗалык субъекты заявкасы күчермәсе;

2) әгәр хуҗалык итүче субъект физик зат булса, физик затның шәхесен таныклаучы документның күчермәсе;

3) шәхесне таныклаучы документның күчермәсе, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза җибәрү датасына кадәр бер ай эчендә алынган өземтә – индивидуаль эшкуарлар өчен;

4) гариза җибәрү датасына кадәр бер ай эчендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә-юридик затлар өчен;

5) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән аренда шартнамәсе яисә түләүсез файдалану шартнамәсе проекты;

6) аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән хисап (тапшыру датасына 30 көннән дә артмаган вакыт белән);

7) хуҗалык итүче субъектның мәдәният оешмасы белән элек төзелгән шартнамәләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булуы (булмавы) турында белешмә.

6. Оешмага хуҗалык итүче ике һәм аннан күбрәк субъектлардан бер үк аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата заявкалар кергән очракта, мөрәҗәгатьләр, заявкалар кергән көннән чыгып, чират тәртибендә җибәрелә.

7. Мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 10 көн эчендә түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерергә;

2) аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тартырга.

8. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага яисә түләүсез файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып:

1) тапшырылган белешмәләрдә һәм әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу;

2) хуҗалык итүче субъект аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән файдаланырга планлаштыра торган чараларның театр-тамаша, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чараларына туры килмәве;

3) хуҗалык итүче субъектның мәдәният оешмасы белән элек төзелгән шартнамәләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булу.

9. Кабул ителгән карар гамәлгә куючы тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты рәвешендә, мөлкәт милекчесе белән килештерелгәннән соң, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты тарафыннан рәсмиләштерелә һәм кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә мәдәният

оешмасына җибәрелә.

10. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага, түләүсез файдалануга тапшыруны килештерүдән баш тарту турында Карар кабул ителгәндә мөрәҗәгать һәм аңа кушып бирелә торган документлар мәдәният оешмаларына мондый карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә кире кайтарыла.

11. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне арендага, түләүсез файдалануга тапшыруны килештерү турында кабул ителгән карар мәдәният оешмасы тарафыннан аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә карата конкурслар яисә аукционнар үткәрмичә генә аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү өчен нигез булып тора.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Мортазин